**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«05» июль 2021 ел №12/1

**«Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 28 октябрендәге «Җир салымы турында» 27/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394, 397 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 22 августта «Җир салымы турында» 27/2 номерлы карарына (2017 елның 25 декабрендәге 33/3, 2018 елның 14 сентябрендәге 42/3, 2018 елның 16 октябрендәге 44/2, 2019 елның 8 ноябрендәге 57/2, 2020 елның 28 февралендәге 61/1, 2021 елның 17 мартындагы 8/1 номерлы каралар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның беренче абзацында «2018 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләр – оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары таныла, дип билгеләргә.

Салым түләүчеләр – оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә карата 2019 елның 1 гыйнвареннан гамәлдә була.

Әлеге карарның 1 пункты 2 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган һәм 2022 елның 1 гыйнвареннан дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Э.Р. Низамиева